СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.09.2018 г. Заинск № 305

**Зәй муниципаль район Советының 2017 елның 15 декабрендәге 256 нчы номерлы «Зәй муниципаль районы муниципаль милкен 2018 елга хосусыйлаштыруның прогноз планы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында»**

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» исемле 2001 елның 21 декабреннән 178 номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» исемле 2003 елның 6 октябреннән 131 номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 31, 77 статьялары нигезендә, шулай ук Зәй муниципаль районы бюджетын тулыландыру максатларында Зәй муниципаль район Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Зәй муниципаль районы муниципаль милкен 2018 нче елга хосусыйлаштыруның проноз планы турында» исемле 2017 нче елның 15 нче декабрендәге 256 нчы номерлы карары белән расланган 2018 нче елга Зәй муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның прогноз планына кушымта нигезендә өстәмә милекне кертергә.
2. Зәй муниципаль районы Советы оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча Зәй муниципаль районы Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе урынбасары** **В. Г. Акатьев**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль район Советының
2018нче елның 10 сентябрендәге
305 нче номерлы Карарына
Кушымта

| № п/п | Объектның исеме | Урнашу урыны | Ниятләнгән гамәлгә ашыру вакыты | Хосусый лаштыру ысулы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Җир участогы белән АКК бинасы (административ-көнкүреш комплекс)<br>Бинаның мәйданы- 286,0 кв.м<br>Җир участогының мәйданы– 244,0 кв.м. | ТР, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Ульянов урамы, 61нче йорт | II яртыеллык, 2018 ел | Аукцион |
| 2 | Җир участогы булган фельдшер-акушерлык пункты (билгеләнеше буенча файдаланылмый))<br>Бинаның мәйданы - 58,5 кв.м.<br>Җир участогының мәйданы – 528,0 кв.м | ТР, Зәй муниципаль районы, Александр Бистәсе авылы, Яңа ур., 21а/2 | II яртыеллык, 2018 ел | Аукцион |
| 3 | 2010 елда чыгарылган FIAT DOBLO 223AXP1A маркалы Автомобиль, Дәүләт теркәү билгесе Н 742 АЕ 116 RUS | ТР, Зәй муниципаль районы,<br>Зәй шәһәре | II яртыеллык, 2018 ел | Аукцион |